| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 29 гыйнвары №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 9678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә кергән хезмәтләр бәясен раслау турында» 2025 елның 29 гыйнварындагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк ав., Мәктәп ур., 3А йорт - үзидарә администрациясе бинасында; Глазово ав., Заречная ур., 13 й.; Петропавловка ав., Горький ур., 19а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниипаль районы
«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.К. Карабаева

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1нче номерлы карарына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 658,54 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып килү | 1 838,93 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2026 елның 29 гыйнварындагы 1нче номерлы карарына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә «Җирләү һәм күмү эше турында» ФЗ-8 12 маддәсе нигезендә күмү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2026 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, сум. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне төрү; | 1 207,32 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2 451,21 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка китерү | 1 838,94 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 181,16 |
| Барлыгы | **9 678,63** |